**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАКТАЛАЧЫК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423751, Такталачык авылы,
Г.Авзал урамы, 48нче йорт.
тел.3-44-57

**ТАКТАЛАЧУКСКИЙ СЕЛЬСКИЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423751, с.Такталачук,
ул.Г.Авзал,
дом 48, тел. 3-44-57

КАРАР
19.06.2019ел.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
№14

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Такталачык авыл җирлеге башкарма комитетының 11.02.2013ел 4 нче санлы « Актаныш муниципаль районы Такталачык авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турындагы» карарына үзгәрешләр кертү турында

2017 елның 29 декабрендәге 479 санлы-ФЗ "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында "Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында" , мөрәҗәгать итүче тарафыннан бердәм гариза бирү юлы белән, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү мөмкинлеген беркетү өлешендә, Актаныш муниципаль районы Такталачык авыл җирлеге Уставы белән, Актаныш муниципаль районы авыл җирлеге **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Такталачык авыл җирлеге башкарма комитетынын 11.02.2013ел 4нче санлы «Башкарма комитет тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турындагы” карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 бүлегенең 5 пунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

- 5) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, күпфункцияле үзәк, әлеге Федераль законның 16 статьясындагы 1_1 өлешендә күрсәтелгән оешмаларның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт яки муниципаль хезмәткәрләрнең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерү буенча судка кадәр (судтан тыш) тәртибе."

1.2. 3.5 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

3.5. Административ регламент бүлекчәсен әзерләү, мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның яисә муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә дәүләт яисә муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, шулай ук әлеге Федераль законның 16 статьясындагы 1_1 өлешендә каралган оешмаларның карарларына һәм

гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерү тәртибенә карата судка кадәр (судтан тыш)".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында Такталачык авыл җирлеге хәбәрләре бүлегендә урнаштырырга.

3.Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Такталачык авыл җирлеге
Башкарма комитеты Җитәкчесе И.С.Шамсунов
.